# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 18 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Саклаубаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган һәрбер кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә үзара салым кертергә килешәсезме:
- элмә такталар һәм аншлагларны буяу өчен буяу сатып алу:
-МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
-Саклаубаш т.п.на агач үсентеләре сатып алу ;
-Саклаубаш т.п.на триммер сатып алу;
- генераторга һәм триммерга бензин сатып алу;
- Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Саклаубаш авылында мәдәни чаралар өчен Бүләкләр, Бүләкләр алу;
- Саклаубаш т.п.на балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру:
- Саклаубаш т.п.на вак таш катлавы ташу һәм урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _382_ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - _241_ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен _241_катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен _0_ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Саклаубаш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш аылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Саклаубаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган һәрбер кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
- элмә такталар һәм аншлагларны буяу өчен буяу сатып алу:

-МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
-Саклаубаш т.п.на агач үсентеләре сатып алу ;
-Саклаубаш т.п.на триммер сатып алу;
- генераторга һәм триммерга бензин сатып алу;
- Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Саклаубаш авылында мәдәни чаралар өчен Бүләкләр, Бүләкләр алу;
- Саклаубаш т.п.на балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру:
- Саклаубаш т.п.на вак таш катлавы ташу һәм урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина